Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы һәм Яңа Кыязлы торак пунктларында 2020 елда үзара салым кертү турында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

28 нче ноябрь 2019нчы ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми ринциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы һәм Яңа Кыязлы торак пунктларының халык җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы һәм Яңа Кыязлы авылларында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә кулланырга:

**Торак пункт чикләрендәге җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзекләндерү:**

-Иске Кыязлы һәм Яңа Кыязлы торак пунктларындагы урамнарны төзекләндерү(балчык белән күтәртү, вак таш сатып алу һәм җәю, торбалар сатып алу);

- Иске Кыязлы авылнының Үзәк урамына ясалма тигезсезлек билгесе куйдыру;

- Иске Кыязлы һәм Яңа Кыязлы торак пунктларында юлларны кардан чистарту.

**Территорияне төзекләндерү:**

-- Иске Кыязлы һәм Яңа Кыязлы торак пунктлары өчен урам утлары сатып алу.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә. Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Дәүләтшин